КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«23» 03 2023 г. № 54-п

«Татмедиа» Республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгының 2022 елның 18 мартындагы 28-п санлы
«Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне
Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат
чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында»
боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРАМ:

1. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 18 мартындагы 28-п санлы «Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» боерыгына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

преамбулада «2014-2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 18 мартындагы 28-п санлы боерыгы белән расланган халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс уздыру турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктында «2014-2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Массакүләм мәгълүмат чараларында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын яктыртуга юнәлдерелгән иң яхшы медиапроект» (1нче, 2нче, 3нче урын).»;

9.1 пунктында «2014-2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.2 пунктында «600,0 мең сум» сүзләрен «575,0 мең сум» сүзләре белән алыштырырга;

9.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинацияләр | Урын | Бүләкләү |
|---|---|---|---|
| 1. | «Массакүләм мәгълүмат чараларында Россия халыкларының мәдәни мирасы елын яктыртуга юнәлдерелгән иң яхшы медиапроект» | 1 урын | 55 000 |
| | | 2 урын | Диплом белән бүләкләнә |
| | | 3 урын | Диплом белән бүләкләнә |
| 2. | «Массакүләм мәгълүмат чараларында Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне яктыртуга юнәлдерелгән иң яхшы медиапроект» | 1 урын | 55 000 |
| | | 2 урын | Диплом белән бүләкләнә |
| | | 3 урын | Диплом белән бүләкләнә |
| 3. | «Массакүләм мәгълүмат чараларында халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне иң яхшы яктырткан материал» | 1 урын | 60 000 |
| | | 2 урын | 50 000 |
| | | 3 урын | 40 000 |
| | | 4 урын | 30 000 |
| 4. | «Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телен, мәдәниятен, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуда гаилә кыйммәтләренең ролен иң яхшы яктырткан материал» | 1 урын | 60 000 |
| | | 2 урын | 50 000 |
| | | 3 урын | 40 000 |
| 5. | «Массакүләм мәгълүмат чараларында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын яктыртуга юнәлдерелгән иң яхшы медиапроект» | 1 урын | 55 000 |
| | | 2 урын | 45 000 |
| | | 3 урын | 35 000 |
| 6. | Барлыгы | | 575 000». |

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев